ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2023 г. Казань № 324-14/кс-2023

«2024-2028 елларга «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.10.2023 № 43-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 кушымтасына туры китереп, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ) өчен ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә су агызуны гамәлгә ашыручы «Ак барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ өчен 2024-2028 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Ак барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат

ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.»;

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.10.2023 № 324-14/кс-2023
карарына 1 кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Ак Барс» кошчылык комплексы» ЖЧЖ өчен 2024-2028 елларга
ташландык суларны агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | |
| 1 | «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 17,37 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 19,88 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 19,56 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 19,56 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 19,56 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 20,94 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 20,94 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 21,00 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 21,00 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 22,15 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.10.2023 № 324-14/кс-2023
карарына 2 кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ өчен 2024-2028 елларга ташландык су агызу тарифларын озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Ташландык су агызу | 2024 | 1 706,84 | x | - | x | 0,846 |
| | | 2025 | x | 1 | - | x | 0,846 |
| | | 2026 | x | 1 | - | x | 0,846 |
| | | 2027 | x | 1 | - | x | 0,846 |
| | | 2028 | x | 1 | - | x | 0,846 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге